Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLIII-13**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгының авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча хисабы турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү һәм авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру өчен уңай шартлар булдыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгының «Балык Бистәсе муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру турында» гы доклады игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:

- халыкның эшлекле активлыгын арттыру, крестьян (фермер) һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга һәм гаилә фермаларына ярдәм итү буенча дәүләт программалары турында аңлату эшләре алып бару;

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны һәм гаилә фермаларын үстерүгә субсидияләнгән кредитлар алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә авыл халкына булышу һәм практик ярдәм күрсәтү;

- шәхси хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын киметмәү, терлек азыгы белән тәэмин итү буенча һәрьяклы ярдәм күрсәтү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов